| Каралган | Килешенгән | Раслыйм |
| --- | --- | --- |
| МБ житәкчесе<br>______ /Нәжметдинова Л.Ә./<br>Беркетмә № 1<br>«25»август 2014 ел. | «Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУ нең УТЭБДУ<br>______ /Сәгъдиева Г.Ф./<br>«25»август 2014 ел. | «Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУ нең директоры<br>______ / Әхмәд... Р.Н./<br>Приказ № 94<br>«27»август 2014 ел. |

Уку фәненнән

# ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы

“Яңа Мәлкән ТГБМ” ГББМУ

Нәҗметдинова Ләлә Әсхәт кызы, икенче квалификацион категорияле укытучы

татар теле, 6 нчы сыйныф

Педагогик совет
утырышында каралган
беркетмә № 1
« 25 »август 2014 ел.

2014 – 2015 нче уку елы

## Аңлатма язуы

**6 нче сыйныфта** татар теленнән эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелә:

1. 2012 нче елның 29 нчы декабреннән гамәлгә кергән“РФ дә Мәгариф турында”273 нче федераль кануны (“Закон об образовании в РФ”)
2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы кануны.
3. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы.
4. Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 933/14 нче №лы боерыгы белән расланган урнәк программа.
5. Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа (5-9 нчы сыйныфлар) / Төзүче-авторлар – М.З.Зәкиев, Н.В.Максимов,– Казан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, 2013.
6. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының “Федераль дәүләт белем стандартлары нигезендә мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту турында”гы 17291/14 №лы хаты (04.09.2014.)
7. ТРның гомумбелем мәктәпләре өчен чыгарылган базис уку-укыту планы (2012 нче ел)
8. “Яңа Мәлкән ГБМУ” ның 2014/15 нче уку елына уку-укыту планнары (25.08.2014 нче ел датасы белән чыгарылган 91 нче № лы боерык);
9. “Яңа Мәлкән ГБМУ” ның уку фәннәреннән эш программасын төзү турындагы локаль акты (Положение о рабочей программе учебного предмета, курса, дисциплины (модуля) МБОУ «Новомелькенская ООШ» Мензелинского муниципального района РТ)

**Мәктәптә татар теле укытуның төп бурычлары** :

1) *коммуникатив максат*: укучыларны ана телендә иркен сөйләшергә һәм аралашырга, логик эзлекле итеп уйлый белергә, фикерне төгәл, ачык итеп җиткерә белергә өйрәтү; туган телнең аралашуда, рухи-әхлакый нормалар формалашуда һәм дөньяны танып белүдә төп чара булуын, аның эстетик кыйммәтен аңлату;

2) *фәнни максат*: татар теленең фонетик, график, орфографик, орфоэпик, лексик, сүз төзелеше һәм ясалышы, грамматик, стилистик нигезләре турында теоретик мәгълүмат бирү;

3) *тәрбияви максат*: туган телгә ихтирам һәм ярату хисләре тәрбияләү; укучыларда гуманлылык хисләрен тәрбияләү; әти-әниләргә, инвалидларга, ятим балаларга шәфкатьлелек хисләрен тәрбияләү; матурлыкны күрә, тоя белергә өйрәтү; туган як табигатен яратырга өйрәтү; туган илең белән горурлану, аны саклау; сәламәт яшәүнең бер төре булган спорт белән кызыксындыру һ.б.

Әлеге максатларны тормышка ашыру өчен куелган **бурычлар**:

●укучыларның башлангыч мәктәптә татар теленең фонетик, график, орфографик, орфоэпик, лексик, сүз ясалыш, грамматик, стилистик нигезләреннән алган белемнәрен системалаштыру, катлаулырак формаларда өйрәтүне дәвам итү һәм телне тулы бер система буларак күзаллауны булдыру;

●укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерли алу мөмкинлекләрен үстерү, үз фикерләрен дәлилләргә күнектерү;

●телнең төп грамматик чараларын сөйләм процессында куллануга ирешү;

● язма һәм сөйләмә тел чараларын дөрес куллана белергә, аларны чагыштыра һәм кирәклесен сайлый, бәяли белергә өйрәтү

●татар әдәби теле нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллауга, аларны тиешенчә куллана белүгә өйрәтү;
●телнең милли мәдәниятнең чагылышы булуын, тел һәм тарих бердәмлеген аңлату; татар теленең милли-мәдәни үзенчәлегенә төшендерү; татар һәм башка халыкларның рухи мирасына ихтирам тәрбияләү;
●татар халкының этник төркемнәре һәм диалектлары, төрки телләр, татар теле, татар язуы, татар халкының рухи, әхлакый, мәдәни мирасы турында мәгълүмат бирү;
●татар телен иҗтимагый күренеш буларак аңлау, тел нормаларын саклап, тормышның төрле ситуацияләренә бәйле рәвештә тел чараларын дөрес кулланып, аралаша-аңлаша белү;
●тел берәмлекләрен танып, аларны тикшерә, рус теле белән чагыштыра алу һәм аралашуда урынлы куллану күнекмәләрен камилләштерү;
●текст һәм Интернет, электрон уку-укыту ресурслары, башка мәгълүмати чаралар белән эшләү, аннан кирәкле мәгълүматны ала белү һәм шуны тиешенчә үзгәртә алу күнекмәләрен үстерү;
●укучыларның орфографик һәм пунктуацион грамоталылыгын камилләштерү.

**Татар теле фәненең тоткан урыны**

Татар теленнән эш программасы **6 нче сыйныфта** гамәлдәге базис план буенчаһәм ТР Минзәлә муниципаль районы “Яңа Мәлкән төп гомуми белем бирү мәктәбе” гомуми белем муниципаль учреждениесенең 2014- 2015 нче уку елына укыту планы буенча 6 нчы сыйныфта уку елы дәвамында 105 (атнага 3 дәрес) сәгатькә каралган.

Татар теле дәресләре, Ф.Ю.Юсупов, Ч.М.Харисова, Р.Р.Сәйфетдинов. Татар теле. 6 сыйныф. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014 буенча укытыла.

Өстәмә әдәбият буларак Н.В.Максимов төзегән “5 - 7 нче сыйныфлар өчен дидактик материаллар” (Казан,”Мәгариф” нәшрияты, 2003 нче ел), Г.Вәлиева “6 нчы сыйныфта татар теленнән күнегүләр җыентыгы” (“Яңалиф” нәшрияты, 2006 нчы ел), Д.Г.Тумашева “ 6 нчы сыйныф өчен дидактик материаллар”(Казан, “Мәгариф”, 1999) кулланыла.

## 6 нчы сыйныф укучыларының тел осталыклары һәм күнекмәләре

6 нчы сыйныфта бирелә торган осталык һәм күнекмәләр (1-5 сыйныфларда алган белемнәргә өстәп күрсәтелә, ә кайберләре киңәйтелгән күләмдә санап китерелә):
- сүз төркемнәрен һәм аларның үзенчәлекле грамматик билгеләрен тану, мисалларны морфологик һәм өлешчә синтаксик яктан тикшерү;
- теоретик материалларга туры килә торган орфограммаларны мисаллар эченнән табу, сүзләрнең дөрес язылышын дәлилләү, сөйләмдә ярдәмче һәм синоним сүзләрне дөрес куллану, алынма сүзләргә төрләндергеч кушымчалар дөрес ялгау, алмашлыклардан һәм теркәгечләрдән фразаара бәйләнеш чаралары буларак оста файдалану. Текст эчендә цифраларны дөрес язу;
- катлаулы план төзү. План нигезендә сочинениегә материал туплау, аны билгеле бер эзлеклелеккә китерү;
- сөйләм төрләрен (сыйфатлама, хикәяләү һәм хөкем йөртү) аеру, шуларга туры китереп, сочинениеләр язу, телдән, монологик һәм диалогик формаларда сөйләү;
- Текстның эчтәлеген төрлечә (төгәл, кыскартып яки киңәйтеп) сөйләү;

- берәр хәл яки вакыйга хакында мәкалә язу;
- изложение, сочинение һәм башка язмаларны камилләштерү (тулыландыру, редакцияләү);
- эш кәгазьләре төреннән расписка һәм акт язу.

**Уку елы башына укучыларның булган белем һәм күнекмәләренә характеристика**
Узган уку елы нәтиҗәләре буенча татар теленнән белем сыйфаты 67 %.Укучылар тарафыннан узган уку елында түбәндәге белем һәм күнекмәләр үзләштерелде: сүзләрне фонетик яктан, төзелеше һәм сүз төркеменә мөнәсәбәте ягыннан тикшерү; ике баш кисәге дә булган җөмләләрне синтаксик яктан тикшерү; таныш модельләр нигезендә гади һәм кушма җөмләләр төзү;сүзнең мәгънәсен аңлату; сүзләрнең язылышын, тыныш билгеләренең куелышын дәлилләү; җөмлә азагында тиешле тыныш билгеләрен һәм кушма җөмлә өлешләре арасында өтер кую; сузык һәм тартык авазларны язуда дөрес белдерү; татар әдәбителенә рус теле, аның аша башка теллләрдән кабул ителгән сүзләрне аеру, аларның мәгънәсенә төшенү; орфографик, татар теленең аңлатмалы һәм татарча – русча сүзлекләрдән файдалана белү; фразеологик әйләнмәләрнең мәгънәсен аңлау; сүзне мәгънәле кисәкләргә аеру һәм һәрберсенә аңлатма бирү, язуда шуларны шартлы билгеләр белән күрсәтү; ясалышы ягыннан сүз төрләренә аңлатма бирү, кушма сүзләрне дөрес язу; текстның темасын аеру, төп уйны аңлау. Гади план төзү; укыганның эчтәлеген төгәл, кыскартып яки киңәйтеп сөйләү. Сыйфатламалар кулланып, сочинеиеләр язу. Сөйләм телендә һәм язма эшләрдә фикерләрне мөмкин кадәр төгәлрәк белдерү өчен, лексик синонимнардан файдалана белү; эш кәгазьләре төрләреннән хат, мәкалә һәм белешмә яза белү.
**Укучылар бу уку елында үзләштерергә тиешле белем-күнекмәләр:**
6 нчы сыйныфта бирелә торган осталык һәм күнекмәләр (1-5 сыйныфларда алган белемнәргә ӗстәп күрсәтелә, ә кайберләре киңәйтелгән күләмдә санап китерелә):
- сүз төркемнәрен һәм аларның үзенчәлекле грамматик билгеләрен тану, мисалларны морфологик һәм өлешчә синтаксик яктан тикшерү;
- теоретик материалларга туры килә торган орфограммаларны мисаллар эченнән табу, сүзләрнең дөрес язылышын дәлилләү, сөйләмдә ярдәмче һәм синоним сүзләрне дөрес куллану, алынма сүзләргә төрләндергеч кушымчалар дөрес ялгау, алмашлыклардан һәм теркәгечләрдән фразаара бәйдәнеш чаралары буларак оста файдалану. Текст эчендә цифраларны дөрес язу;
- катлаулы план төзү. План нигезендә сочинениегә материал туплау, аны билгеле бер эзлеклелеккә китерү;
- сөйләм төрләрен (сыйфатлама, хикәяләү һәм хөкем йөртү) аеру, шуларга туры китереп, сочинениеләр язу, телдән, монологик һәм диалогик формаларда сөйләү;
- Текстның эчтәлеген төрлечә (төгәл, кыскартып яки киңәйтеп) сөйләү;
- берәр хәл яки вакыйга хакында мәкалә язу;
- изложение, сочинение һәм башка язмаларны камилләштерү (тулыландыру, редаксияләү);
- эш кәгазьләре төреннән расписка һәм акт язу.

***Укыту программасының төп эчтәлеге.***

| № | **Курсның эчтәлеге** | **Сәг.саны** |
|---|---|---|
| 1 | **Тел- иң әһәмиятле аралашу чарасы.** Телнең төп функцияләре. Туган телнең һәрбер халык | **1** |

| | | |
|---|---|---|
| | тормышында һәм кешене шәхес итеп формалаштырудагы роле. | |
| 2 | **Алдагы сыйныфларда үткәннәрне кабатлау.** | **1** |
| 3 | **Морфология турында төшенчә.** Сүз төркемнәре. Сүз төркемнәренең лексик-грамматик төрләре. Сүз төркемнәренең классификациясе. Мөстәкыйль сүз төркемнәре. Аларның семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре. Сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәте. Телнең төп морфологик нормалары. | **1** |
| 4 | **Исем.** Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Берлек һәм күплек сандагы исемнәр. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Сан, тартым һәм килеш кушымчаларын куллануда стилистик төрлелек. Исемнәрнең ясалышы. Сүз ясагыч кушымча ялгану. Сүзләр кушылу ысулы. Фонетик ысул, мәгънә үзгәрү ысулы, бер сүз төркеменнән икенчесенә күчү һәм сүзләрне кыскарту ысуллары. Синоним һәм антоним исемнәр. Исемнәрнең җөмләдә кулланылышы. Исемнәргә морфологик анализ ясау. | **13** |
| 5 | **Сыйфат.** Сыйфат турында гомуми төшенчә. Сыйфат дәрәҗәләре. Сыйфатларның ясалышы. Синоним һәм антоним сыйфатлар. Сыйфат һәм рәвешләрнең уртак һәм аермалы яклары. Сыйфатларның җөмләдә кулланылышы. Сыйфатларга морфологик анализ ясау. | **7** |
| 6 | **Рәвеш.** Рәвеш төркемчәләре. Рәвеш дәрәҗәләре. Рәвешләрнең ясалыш ягыннан төрләре һәм дөрес язылышы. Рәвешләрнең җөмләдә кулланылышы. Рәвешләргә морфологик анализ ясау. | **7** |
| 7 | **Сан.** Сан турында гомуми төшенчә. Сан төркемчәләре. Микъдар саны. Тәртип саны. Чама саны. Бүлем саны. Җыю саны. Саннарның җөмләдә кулланылышы. Саннарга морфологик анализ ясау. | **7** |
| 8 | **Алмашлык.** Алмашлык турында гомуми төшенчә. Алмашлык төркемчәләре. Зат алмашлыклары. Күрсәтү һәм билгеләү алмашлыклары. Сорау алмашлыклары. Юклык һәм билгесезлек алмашлыклары. Тартым алмашлыклары. Алмашлыкларның җөмләдә кулланылышы. Алмашлыкларга морфологик анализ ясау. | **8** |
| 9 | **Фигыль.** Фигыль турында төшенчә. Фигыльнең башлангыч формасы, барлык- юклык төре. Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Фигыль юнәлешләре. Фигыль төркемчәләре. Боерык фигыль. Хикәя фигыль. Хәзерге заман хикәя фигыль. Үткән заман хикәя фигыль. Киләчәк заман хикәя фигыль. Шарт фигыль. Сыйфат фигыль. Сыйфат фигыльнең заман формалары. Хәл фигыль. Исем фигыль. Инфинитив. | **24** |

| | | |
|---|---|---|
| | Фигыльләрнең ясалыш ягыннан төрләре, җөмләдә кулланылышы. Фигыльләргә морфологик анализ ясау. | |
| 10 | **Аваз ияртемнәре.** | **1** |
| 11 | **Хәбәрлек сүзләр.** | **1** |
| 12 | **Ярдәмлек сүз төркемнәре.** Бәйлек һәм бәйлек сүзләр.<br>Теркәгечләр. | **4** |
| 13 | **Модаль сүз төркемнәре.** Кисәкчәләр. Кисәкчәләрнең төркемчәләре.<br>Модаль сүзләр. Ымлыклар. Хәбәрлек сүзләр. | **5** |
| 14 | **Кабатлау** | **3** |
| 15 | Диктант (Контроль диктант)+ 2 конроль тест | 9(4)+2=11 |
| | **Бәйләнешле сөйләм үстерү (БСҮ) – 11,** шуның 6 (2) изложение, 5се –сочинение, 2 се – эш кәгазьләре язу | 11 |
| | **Барысы:** | ***105 сәгать*** |

## Гомумбелем күнекмәләрен бәяләүнең критерийлары һәм нормалары

**Язма эшләрнең күләме һәм аларны бәяләү:**

Сүзлек диктанты –20-25 сүз

**Сүзлек диктантын бәяләү**

1. Пөхтә язылган, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела.
2. Бер орфографик хаталы эшкә “4” ле куела.
3. Өч орфографик хаталы эшкә “3”‖ ле куела.
4. Биш орфографик хаталы эшкә “2” ле куела.

Контроль диктант- ел башында 110 сүз, ел ахырында 120 сүз

**Контроль диктантны бәяләү:**

1. Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаган эшкә ―5‖ ле куела. (Бер – орфографик, ике пунктуацион хата булырга мөмкин.)
2. Ике орфографик, ике пунктуацион яки бер орфографик, дүрт пунктуацион хаталы эшкә ―4‖ куела.

3. Дүрт орфографик, дүрт пунктуацион яки өч орфографик, алты пунктуацион хаталы эшкә ―3‖ куела.
4. Алты орфографик, биш пунктуацион яки биш орфографик, сигез пунктуацион хаталы эшкә ―2‖ куела.

**Изложение текстының күләме**

ел башында 200-220 сүз (120-130 –язма күләме)
ел ахырында 220-250 сүз (130-140- язма күләме)

**Изложениене бәяләү**

1. Тема тулысынча ачылган, фактик һәм техник хаталары булмаган, стиль бердәмлеге сакланган эшкә «5» ле куела. (Бер орфографик, ике пунктуацион яки ике грамматик хатасы булырга мѳмкин.)
2. Текстның эчтәлеге темага нигездә туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлыклар җибәрелсә, бер-ике фактик, бер-ике техник хатасы булса, ике орфографик, ике-өч пунктуацион, бер грамматик хатасы булган эшкә «4» ле куела.
3. Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сакланмаса өч фактик, ике-өч техник хатасы булса, өч орфографик, дүрт пунктуацион, ике грамматик хатасы булган эшкә «3» ле куела.
4. Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталары күп булса, орфографик хаталарның саны дүрттән, пунктуацион хаталарның саны биштән, грамматик хаталар саны өчтән артса, «2» ле куела. Сочинениенең күләме һәм аны бәяләү

Иҗади эшнең бер төре буларак, сочинение — укучының язма рәвештә үти торган эше. Ул бәйләнешле сөйләм үстерү күнекмәләре булдыруда зур әһәмияткә ия. Әдәби (хикәяләү, очерк, истәлек, хат, рецензия һ. Б.), әдәби- иҗади, өйрәтү характерындагы, ирекле, рәсемнәр нигезендә үткәрелә торган һәм контроль сочинениеләр була.

**Сочинениене бәяләү**

1. Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килсә, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге сакланса, «5» ле куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин.)
2. Язманың эчтәлеге нигездә темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлыклар күзәтелсә, бер-ике фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, ике орфографик, өч пунктуацион (грамматик) яисә бер-ике сөйләм ялгышы булса, «4» ле куела.
3. Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, өч орфографик, дүрт пунктуацион (грамматик) яисә өч-дүрт сәйләм хатасы булса, «3» ле куела.
4. Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендә язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, биш орфографик, сигез пунктуацион (грамматик) яисә дүрт—алты сөйләм хатасы булса, «2» ле куела.

**Татар теленнән V-IX классларда бәйләнешле сөйләм үстерү сәгатьләренең якынча бүленеше**

| Класс | Диктант | Изложение | Сочинение | Эш кәгазьләре | БСҮ |
|---|---|---|---|---|---|
| V (22 сәг.) | 8(4) | 6(2) | 3(1) | Белешмә – 1 сәг.<br>Хат язу – 1 сәг. | Мәкалә язу – 1 сәг.<br>Язма эшләрне бергәләп тикшерү – 2 сәг. |
| VI (24 сәг.) | 8(4) | 6(2) | 3(1) | Расписка язу – 1 сәг.,<br>Акт язу – 1 сәг. | Мәкалә язу – 1 сәг.<br>Язма эшләрне (сочинение, изложение) бергәләп тикшерү – 2 сәг.<br>Сочинениегә материал туплау, аларны эзлекле тәртипкә китерү – 1 сәг. |
| VII (23 сәг.) | 8(4) | 5(2) | 3(1) | Гариза язу – 1 сәг.<br>Хат язу – 1 сәг.<br>Акт язу – 1 сәг. | Мәкалә язу – 1 сәг.<br>Язма эшләрне (сочинение, изложение) бергәләп тикшерү – 2 сәг.<br>Сочинениегә материал туплау, аларны эзлекле тәртипкә китерү – 1 сәг. |
| VIII (21 сәг.) | 8(2) | 5(2) | 3(1) | Беркетмә язу – 2 сәг. | Язма эшләрне (сочинение, изложение) бергәләп тикшерү – 2 сәг.<br>Сочинениегә материал туплау, аларны эзлекле тәртипкә китерү – 1 сәг. |
| IX (16 сәг.) | 4(2) | 2(1) | 4(2) | Шартнамә язу – 1 сәг.<br>Ышанычнамә язу – 1 сәг. | Конспект, тезис турында башлангыч төшенчә – 2 сәг.<br>Язма эшләрне (сочинение, изложение) бергәләп тикшерү – 1 сәг.<br>Сочинениегә материал туплау, аларны эзлекле тәртипкә китерү – 1 сәг. |

## VI класста татар теленнән үзләштерелергә<br>һәм камилләштерелергә тиешле гомум күнекмәләр

| Уку эшчәнлеген оештыра белү юнәлешендә | Китап, өстәмә мәгълүмат белән эш итә белү | Фикерләү белән бәйле күнекмәләр | Телдән һәм язма сөйләм үстерү һәм аралаша белү юнәлеше |
|---|---|---|---|
| 1. Уку мәсьәләләрен мөстәкыйль билгеләү.<br>2. Уку операцияләрен планлаштыру.<br>3. Белем алуның рациональ ысулларын сайлау.<br>4. Үз-үзеңә контроль ясауның төрле формаларын үзләштерү.<br>Мөстәкыйль белем алу буенча эш | 1. Дәреслек белән эш итә белү.<br>2. Төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эш итә белү.<br>3. Төрле текстлар белән эш иткәндә сәнгатьлелекне саклый белү.<br>4. Эчтәлекне аңлап, тиешле тизлектә, дөрес уку:<br>- уку елы башында — 70-110 сүз;<br>- уку елы ахырында — 75-115 сүз.<br>5. Сүзлекләрдән файдалана белү, | 1. Уку мәсьәләсен куя белү.<br>2. Танып белү активлыгын үстерү.<br>3. Яңа теманы аңлауга мотив тудыру.<br>4. Төшенчә, термин, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү күнекмәсен камилләштерү.<br>5. Логик алымнардан чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау күнекмәләрен камилләштерү.<br>6. Грамматик анализ төрләрен үзләштерү:<br>• мөстәкыйль сүз төркемнәренә морфологик анализ;<br>• ярдәмлек сүз төркемнәренә | 1. Телдән сөйләм:<br>• кагыйдәләрне аңлап эзлекле сөйли белү күнекмәсе;<br>• сорауны формалаштыра белү һәм тулы җавап бирә белү күнекмәсе.<br>2. Язма сөйләм:<br>• күчереп язу;<br>• сүзлек диктанты — 20-25 сүз;<br>• контроль диктант — 110-120 сүз,<br>• катлаулы план буенча изложение язу:<br>- уку елы башында — 200-220 сүзле текст (язманың күләме — 120-130 сүз); |

| | | | |
|---|---|---|---|
| башлау. | белешмә әдәбият белән системалы эшләү.<br>6. Китапханәдә систематик каталог белән эш итә белү.<br>7. Аудио-видео белән эш итә белү. | морфологик анализ.<br>7. Тикшеренү ысуллары:<br><br>• модельләштерү;<br>• охшатып эшләү. | - уку елы ахырында — 220-250 сүзле текст (язманың күләме — 130-140 сүз);<br><br><br>• фикер йөртү элементлары кертеп, гади яки катлаулы план төзеп сочинение язу;<br>• эш кәгазьләре язу (акт һәм расписка). |

## Календарь-тематик планлаштыру

Татар теле
6 класс
**Укытучы** <u>Нәҗметдинова Ләлә Әсхәт кызы</u>
**Сәгатьләр саны 105, атнага <u>3</u> сәгать.**
**Контроль дәресләр:**
Диктантлар – <u>8 (4)</u>
Изложениеләр – <u>6 (4)</u>
Сочинениеләр–<u>5 (2)</u>
**Административ контроль дәресләр 2 сәгать.**

**Тематик планлаштыру:** Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа (5-9 нчы сыйныфлар) /Төзүче-авторлар – М.З.Зәкиев, Н.В.Максимов,– Казан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, 2013.**нигезендә төзелде.**

**Дәреслек:** Ф.Ю.Юсупов, Ч.М.Харисова, Р.Р.Сәйфетдинов. Татар теле. 6 сыйныф. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014

**Өстәмә әдәбият**
2. Р. Г. Хәсәншина. ―Татар теле дәресләре, методик кулланма. Казан: ―Мәгариф, 2007

3. . Диктантлар җыентыгы: Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 5-11 нче сыйныфлары өчен. З.Н.Хабибуллина, Г.Ш.Нәбиуллина.-Казан: Мәгариф,2006.

4. Татар теленнән диктантлар һәм изложениеләр җыентыгы: Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 5-11 с-флары өчен. Н.В.Максимов, С.М.Трофимова, М.З.Хәмидуллина.-Казан: Мәгариф, 2005

5. “5 - 7 нче сыйныфлар өчен дидактик материаллар” Н.В.Максимов (Казан,”Мәгариф” нәшрияты, 2003 нче ел),

6. “6 нчы сыйныфта татар теленнән күнегүләр җыентыгы” Г.Вәлиева (“Яңалиф” нәшрияты, 2006 нчы ел),

7. “ 6 нчы сыйныф өчен дидактик материаллар” Д.Г.Тумашева (Казан, “Мәгариф”, 1999),

# Тематик план

| № | Бүлекләр һәм темалар | Сәг. Саны | Дәрес тибы | Көтелгән нәтиҗә | | | Контроль төре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Махсус белем | План | факт | | План | факт |
| 1 | Татар әдәби теле хакында әңгәмә. | **1** | Комплексלы | Телнең кеше һәм җәмгыять тормышы белән бәйләнешен ачыклау | Әдәби тел һәм матур әдәбият теле төшенчәләрен аеру | Фәнни сөйләм культурасын үстерү. | Хикәя “Җәйге бер көн”. | 02.09 | |
| 2 | Кабатлау. Җөмлә кисәкләре.<br>Ясалышы ягыннан сүз төрләре. | **1** | Белемнәрне актуальләштерү | Җөмлә кисәкләре, Сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен турындагы белемнәрне актуальләштерү | Төшенчәләрнең билгеләмәләрен әйтә белү. | Модельләштерү, модельне уку күнекмәсен камилләштерү. | Кечкенә күләмле сочинение «Көзге урман». | 03.09 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | **Морфология.** Морфология турында төшенчә . | **1** | УМ кую | Морфология төшенчәсен формалаштыру, сүз төркемнәре турында белгәннәрне актуальләштерү, аларны төркемләү үзенчәлекләрен аңларга ярдәм итү | Сүз төркемнәрен тану һәм аеру ысулларын билгеләү. | Абстракт тәшенчәне конкрет өлешләргә тарката белү күнекмәсен үстерү. | Мөстәкыйль эш. | 05.09 | |
| 4 | **СҮ. Үтелгәннәрне кабатлауга тикшерү диктанты.** | **1** | Контроль | | Дөрес язу күнекмәләрен камилләштерү. | Төркемнәрдә ярдәмләшеп эшләү күнекмәсен үстерү | Аңлатмалы диктант | 09.09 | |
| 5 | **Мөстәкыйль сүз төркемнәре.** Исем. -13 сәг. Исемнәрнең мәгънә төркемчәләре. | **1** | УМ кую һәм чишү | Исем турында белгәннәрне системалаштыру, ялгызлык һәм уртаклык исемнәр исемнәр төшенчәсен тулыландыру | Исемнең үзенчәлекле грамматик билгеләрен тану, ялгызлык һәм уртаклык исемнәрне дөрес язу. | Дәреслек белән эшләү күнекмәсен камилләштерү. | Сүзлек диктанты. (Ялгызлык, уртаклык исемнәр). | 10.09 | |
| 6 | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше | **1** | УМ кую һәм чишү | Исемнең грамматик билгеләрен өйрәнү. | Исемне берлек һәм күплек санда куллана белү, килешләрдә төрләндерү | Язу темпы өстендә эшләү, тигез һәм бергә язу күнекмәсен үстерү | Шигырь «Күзгә яңгыр нисөйли?» | 12.09 | |
| 7 | Исем. Баш килеш. | **1** | УМ кую һәм чишү | Баш килештәге исемне кулланудагы үзенчәлекләрне | Баш килештәге исемне берлек һәм күплек санда куллана белү | Дәреслек белән эшләү күнекмәсен камилләштерү | Мөстәкыйль эш | 16.09 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | күзәтү, аңларга ярдәм итү | | | | | |
| 8 | Исем. Иялек килеше. | **1** | УМ кую һәм чишү | Иялек килеше кушымчаларын кулланудагы үзенчәлекләрне күзәтү, аңларга ярдәм итү | Иялек килеше кушымчаларын сөйләмдә дӛрес куллану | Төркемнәрдә ярдәмләшеп эшләү күнекмәсен үстерү. | Кагыйдә буенча сораулык. | 17.09 | |
| 9 | Исем. Юнәлеш килеше. | **1** | УМ кую һәм чишү | Юнәлеш килеше кушымчаларын кулланудагы үзенчәлекләрне күзәтү | Исемнәрне килешләрдә төрләндерү. | Дәреслек белән эшләү күнекмәсен камилләштерү | Тест | 19.09 | |
| 10 | Исем. Тӛшем килеше. | **1** | УМ кую һәм чишү | Төшем килеше кушымчасын кулланудагы үзенчәлекләрне күзәтү | Төшем килеше кушымчаларын сөйләмдә дөрес куллану | Төркемнәрдә ярдәмләшеп эшләү күнекмәсен үстерү | Мөстәкыйль эш | 23.09 | |
| 11 | Исем. Чыгыш килеше. | **1** | УМ кую һәм чишү | Чыгыш килеше кушымчасын кулланудагы үзенчәлекләрне күзәтү | Исемнәрне килешләрдә төрләндерү. | Дәреслек белән эшләү күнекмәсен камилләштерү | Тест | 24.09 | |
| 12 | Исем. Урын-вакыт килеше. | **1** | УМ кую һәм чишү | Урын-вакыт килеше кушымчаларын кулланудагы үзенчәлекләрне күзәтү, аңларга ярдәм итү. | Исемнәрне килешләрдә төрләндерү. | | | 26.09 | |
| 13 | **БСҮ.** Изложение язу. — «Урманнарны саклагыз» | **1** | Иҗади | Укытучы укыганны тыңлый, | Тартым, килеш кушымчаларын урынлы | Ишеткәнне текстка якын итеп, эзлекле | Изложение | 30.09 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | эчтәлекне дөрес аңлый белү. | куллану. | рәвештә язу күнекмәсе формалаштыру | | | |
| 14 | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. | **1** | УМ куюһәм чишү | Тартым төшенчәсен формалаштыру. | Тартымлы исемнәрне тану һәм аеру | Таблица белән эшләү күнекмәсен камилләштерү | Мөстәкыйль эш | 01.10 | |
| 15 | Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. | **1** | УМ куюһәм чишү | Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнешендә булган үзенчәлекләрне аңларга ярдәм итү. | Тартымлы исемнәрне килешләр белән төрләндерә белү | Таблица белән эшләү күнекмәсен камилләштерү | Диктант – 7 мин. | 03.10 | |
| 16 | Тартымны белдерү юллары. | **1** | УМ куюһәм чишү | Тартым төшенчәсен белдерүдәге тӗрлелек. Сан, тартым һәм килеш кушымчаларының тиңдәш кисәкләрдә кулланылу үзенчәлекләре. | Тартым, килеш кушымчаларын урынлы куллану. | Сөйләм культурасын үстерү. | Сорауларга җавап бирү. | 07.10 | |
| 17 | **БСҮ:** фикер йөртү тибындагы сочинение язу. **(контроль) “** Кешене хезмәт бизи” | **1** | Иҗади | Фикер йөртү төренә караган сочинение язу тәртибен үзләштерү | Эзлекле сөйләм төзү. | Сөйләм культурасын камилләштерү | Фикер йөртү төрендәге сочинение | 08.10 | |
| 18 | Исемнәрнең ясалышы. | **1** | УМ куюһәмчи | Исемнәрнең ясалышы турында | Сүз ясагыч кушымчалар ярдәмендә | Модельләштерү күнекмәсен үстерү | Сүзлек диктанты. | 10.10 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шү | төшенчә формалаштыру, исем нәрне төркемләү принцибын үзләштерү | исемнәр ясау күнекмәсен үстерү | | | | |
| 19 | Исемнәрне гомумиләштереп кабатлау. Исемгә морфологик анализ | **1** | Белемнәрне актуальләштерү | Исемнәрне морфологик яктан тикшерү тәртибен үзләштерүгә ярдәм итү | Исемгә морфологик анализ ясау. | Дәреслек белән эшләү күнекмәсен камилләштерү | Кисем. | 14.10 | |
| 20 | **Контроль эш:** тестлы биремнәр үтәү | **1** | Контроль | Үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау, темаларның үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү | Тематик тест биремнәрен мөстәкыйль эшләү. | Мөстәкыйль эшләү. | Тест | 15.10 | |
| 21 | **Сыйфат.** -8 сәг. | **1** | УМ кую һәм чишү | Сыйфат турында төшенчә формалаштыру, сыйфат дәрәҗәләре, аларның мәгънә һәм ясалыш үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итү. | Сыйфатланмыш төшенчәсен дөрес куллану, сыйфат дәрәҗәләрен тану һәм аеру | Дәреслек белән эшләү күнекмәсен камилләштерү. | Сорауларга җавап бирү | 17.10 | |
| 22 | Сыйфат дәрәҗәләре. | **1** | УМ кую һәм чишү | Сыйфатларның сөйләмдәге әһәмиятен ачыкларга ярдәм итү | Сыйфатларны сөйләмдә урынлы куллану күнекмәсен үстерү. | Модельләштерү күнекмәсен үстерү | Сүзлек диктанты. | 21.10 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 23 | **Бсү.** К. Максимовның “Натюрморт” картинасы буенча сочинение-тасвирлама язу | **1** | Иҗади | Тасвирлама сочинение язу үзенчәлеген аңларга ярдәм итү | Эзлекле сөйләм төзү. | Өстәмә чыганаклардан файдалану күнекмәсен үстерү. | Тасвирлама сочинение язу | 22.10 | |
| 24 | Асыл һәм нисби сыйфатлар | **1** | УМ кую һәм чишү | Асыл һәм нисби сыйфатларны аера белү. | Сыйфатларны сөйләмдә урынлы куллану күнекмәсен үстерү. | Дәреслек белән эшләү күнекмәсен камилләштерү | Сорауларга җавап бирү. | 24.10 | |
| 25 | Сыйфатларның җөмләдә кулланылышы. Сыйфатларга морфологик анализ ясау. | **1** | УМ кую һәм чишү | Сыйфатларның җөмләдәге ролен билгеләү үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итү. | Сыйфатларга морфологик анализ ясау | Модельләштерү күнекмәсен үстерү | Сорауларга җавап бирү. | 28.10 | |
